# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ, март, 2025 ел № 5

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***


1. ***Кояш гомере телим мин, әнием сиңа!***
2. ***Тәрәз төбем гөлбакча***
3. ***Куркынычсызлык кагыйдәләрен сакла!***
4. ***“Тылсымлы келәм” (дидактик уен)***


**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**

***Яз белән бергә матур бәйрәм - 8 Март - Халыкара хатын-кызлар көне дә килде. Безнең өчен бу иң яраткан бәйрәм.***

Шулай итеп, безнең бакчада да беренче язгы бәйрәм 8 нче март уңаеннан балалар иртәсе үткәрелде. Бәйрәмдә күңелле атмосфера хөкемсөрде, бик күңелле һәм кызыклы булды. Балалар шигырьләр сөйләделәр, әниләр һәм әбиләр турында матур җырлар җырладылар, төрле уеннар уйнадылар.

Әниләре өчен балалар үз куллары белән ясалган бүләкләр – искиткеч открыткалар әзерләделәр, аларга барлык җылы хисләрен һәм мәхәббәтләрен керттеләр. Мондый бәйрәм, һичшиксез, балалар бакчасы тормышына язгы шатлык һәм бәхет атмосферасы алып килә.











## *ТӘРӘЗ ТӨБЕМ ГӨЛБАКЧА*

Һәр елны март ае башында бакчабызның тәрәзә төбендә яшелчә бакчасы ясыйбыз. Быел без анда ике төрле ысул белән суган утырттык. Шулай ук редиска, укроп, петрушка чәчтек. Шөгелебезнең максаты – табигатьне саклаучы, мәрхәмәтле шәхесләр тәрбияләү, эш гамәлләр турында сүзлек запасын арттыру, орлыкларны дөрес итеп чәчәргә өйрәтү һәм хезмәт тәрбиясе бирү.

Эшне башлар алдыннан бакчабыз өчен кирәк-яраклар әзерләдек һәм балалар белән яшелчәләрнең сәламәтлек өчен файдалы булуы турында әңгәмә уздырдык. Балалар суган утыртты, һәр төркем үзенә йөкләнгән яшелчә орлыкларын савытларга чәчтеләр. Суганнарның нинди мохиттә яхшырак үсүен белү өчен, суганны 2 төрле ысул белән утырттык. Яшелчәләрне тәрбияләү өчен дежурлар билгеләдек.









**Ел саен 1 март көнне Бөтендөнья гражданнар оборонасы көне билгеләп үтелә. Бу тема мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен дә бик мөһим. Безнең балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге балалар иминлеге беренче урында тора**.

Бөтендөнья гражданнар оборонасы көне кысаларында гадәттән тыш хәлләрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру өчен «Минем куркынычсызлык» темасына шөгыль уздырылды. Балалар гадәттән тыш хәлләр турында булган белемнәрен, янгын, террорчылык актлары килеп чыкканда үз-үзләрен куркынычсыз тоту кагыйдәләрен ныгыттылар, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда мөстәкыйль эш итәргә өйрәнделәр. Балалар иллюстрацияләр карадылар, катлаулы хәлләр турында фикер алыштылар, табышмаклар чиштеләр, төрле уеннар уйнадылар. Гражданнарны яклау стенды белән таныштылар.

Бакчабызда гадәттән тыш хәлләр бүлегендә эшләүче, безнең бакчада тәрбияләнүче Алинә һәм Әминә Гатауллиналарның эти-әнисе – Айдар һәм Алсу Гатауллиннар безнең даими кунакларыбыз. Алар һәрвакыт балаларга үзләренең хезмәтләренең җаваплы һәм авыр булуы турында сөйлиләр. Балаларга куркыныч янаган вакытта үз-үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында аңлаталар.











Балаларның бай рухлы, сау-сәламәт булып үсүендә уеннарның әһәмияте зур. Шуны истә тотып без балалар өчен кызыклы булган яңа уеннар ясау өстендә һәрдаим эшләп торабыз. Шуның соңгы ясалганы **“Тылсымлы келәм”** дип атала.

**Уенның максаты:** балаларда илне саклаучы хәрбиләр һәм хәрби техника, армиябез белән горурлану; гаскәрләр турында күзаллау формалаштыру.

Балаларда Россия һәм Татарстанның дәүләт символларына карата хөрмәт һәм ихтирам, Ватанга мәхәббәт, яшь буында милли горурлык, патриотлык хисләре тәрбияләү – балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләрнең төп бурычы.

2025 ел – Ватанны саклаучылар елында бу уен аеруча актуаль.

Бу уен илебез патриотлары тәрбияләү өчен бик уңышлы килеп чыкты дип саныйбыз.







